ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУСЛЮМОВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МӨСЛИМ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

_15.11.2021_ М ө с л и м №_527_

**Мөслим муниципаль районы Башкарма комитеты карарларын гамәлдән чыгару турында**

Россия Федерациясе Торак кодексының 20 статьясы, «Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында» 2020 елның 31 июлендәге 248-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Башкарма комитеты **КАРАР БИРДЕ:**

1. Гамәлдән чыгарырга:

1.1. «Мөслим муниципаль районы территориясендә муниципаль торак фондыннан файдалануга һәм аны саклауга, әлеге фондның торак урыннарының билгеләнгән санитария һәм техник кагыйдәләргә һәм нормаларга, законнарның башка таләпләренә туры килүенә муниципаль контрольне гамәлгә ашыру буенча административ регламентны раслау турында» 2019 елның 14 июнендәге 278 номерлы Мөслим муниципаль районы Башкарма комитеты карарын;

1.2. «Мөслим муниципаль районы территориясендә муниципаль торак фондыннан файдалануга һәм аны саклауга, әлеге фондның торак урыннарының билгеләнгән санитария һәм техник кагыйдәләргә һәм нормаларга, законнарның башка таләпләренә туры килүенә муниципаль контрольне гамәлгә ашыру буенча административ регламентны раслау турында» 2018 елның 1 июлендәге 274 номерлы Мөслим муниципаль районы Башкарма комитеты карарын.

2. Әлеге карарны Интернет мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә Мөслим муниципаль районының рәсми сайтында (http://muslumovo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) бастырырга.

**Башкарма комитет җитәкчесе** **А.Р.Хужин**